КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 18 август

г.Казань

№ 701

«Педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификациясен бәяләү үзәге» дәүләт автоном учреждениесен оештыру турында

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 – 2022 елларда федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү өчен Россия Федерациясе субъектларын сайлап алу комиссиясе утырышының 2019 елның 15 июлендәге МР-23/02б номерлы «Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында «Педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын һәм квалификацияләрен бәяләү үзәкләре һәм педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын өзлексез күтәрү үзәкләрен булдыру» чарасы буенча беркетмәсен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында педагог хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын һәм квалификациясен өзлексез күтәрү үзәкләрен һәм педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификацияләрен бәяләү үзәген оештыру чараларын тормышка ашыру турында» 2019 ел, 02 июль, 534 нче карарын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 1 сентябреннән «Педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификациясен бәяләү үзәге» дәүләт автоном учреждениесен (алга таба – Үзәк) төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Үзәк эшчәнлегенең төп максаты – педагогик хезмәткәрләрнең һәм белем бирү оешмалары җитәкчеләренең квалификациясен бәйсез бәяләү уздыру;

үзәкне гамәлгә кую функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы гамәлгә ашыра.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

30 көн эчендә Үзәкнең уставын расларга һәм аны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

Үзәк уставын дәүләт теркәвенә алганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Үзәккә беркетү өчен мөлкәт, шул исәптән аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәт исемлеген җибәрергә;

30 көн эчендә законнарда каралган башка оештыру-хокукый чараларны, шул исәптән хезмәт хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә дә, гамәлгә ашырырга;

ел саен билгеләнгән тәртиптә Үзәк өчен, аның уставында каралган төп эшчәнлек нигезендә, дәүләт йөкләмәсен расларга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән мөлкәт исемлеге тапшырылганнан соң, аны Үзәккә оператив идарә итү хокукында беркетергә.

5. Гамәлгә куючының дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү Үзәк тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертергә һәм билгеләнгән тәртиптә «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр тапшырырга.

7. »Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, әлеге карарның 3 – 6 пунктларын үтәгәннән соң 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы социаль-мәдәни өлкәсенең аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2009 елның 23 сентябрендәге 872 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында карары проектын әлеге карарның 1 пунктына туры китерү өлешендә эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга тапшырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин